**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2024 № 720

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Табибларга - яшь белгечләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2008 елның 1 ноябрендәге 646 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 31 декабрендәге « Яшь белгеч- табибларга дәүләт ярдәме чаралары турында» 1187 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең « Яшь белгеч- табибларга дәүләт ярдәме чаралары турында » 2008елның 1 ноябрендәге 646 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. беренче абзацта « Яшь белгеч- табибларга дәүләт ярдәме чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 4 июнендәге 210 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 13 октябрендәге 740 номерлы карары белән "Яшь белгеч - табибларга дәүләт ярдәме чаралары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 31 декабрендәге 1187 номерлы карары белән сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының сәламәтлек саклау учреждениеләрендә табибларга - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибендә:

4 пунктта « уртача хезмәт хакын исәпләгәндә.» сүзләрен « яшь белгечләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бирү максатларында уртача хезмәт хакын санаганда» сүзләренә алмаштырырга.»;

түбәндәге эчтәлекле 7 пунктны өстәргә:

«7. Әгәр әлеге карарның 1 пункты нигезендә яшь белгечкә айлык өстәмә (бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү) күләме әлеге карар кабул ителгәнче табиб-белгечкә билгеләнгән айлык өстәмәнең (бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүнең) күләменнән түбәнрәк булса, мондый хезмәткәр өчен күрсәтелгән өстәмәнең (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең) элекке күләмдә түләнүе сакланып кала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин